СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«14» август, 2024 ел Алабуга шәһәре № 372

«Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хаында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Алабуга муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, шулай ук Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Алабуга шәһәре» һәм «Бехтерев авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан күрсәтелгән җирләрне «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә «Бехтерев авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чигенә кертү юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы чикләрен Удмурт Республикасы белән чиктәш җирләрдә туры китерү нигезендә, «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына кергән «Олы Шүрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртүгә җирлектәге халыкның ризалыгын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә һәм аңа материаллар кертергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән проектны

караганда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы Р.М. Нуриевны Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы вәкиле итеп билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр төзелеше, инфраструктура үсеше һәм туризм мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов